ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1364 2018 елның 3 июле

# Канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьяның 7 пункты нигезендә, йөклим:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен расларга.

2. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 3 июлендәге
1364 номерлы күрсәтмәсенә
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләвен билгеләү кагыйдәләрен билгели (алга таба - мәдәни мирас объектлары).

2. Ташламалы аренда түләвен билгеләү шартлары булып тора:

мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларына кертү критерийлары нигезендә канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы «Канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектларына Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын кертү критерийларын раслау турында» карары белән расланган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектларына кертү;

арендаторның «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 47.6. статьясында каралган саклау йөкләмәсе нигезендә, мәдәни мирас объектын саклау буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә аны арендага биргән көннән ике елдан артмаган вакыт эчендә мәдәни мирас объектын саклауның проект документларын әзерләү һәм килештерү срогын кертеп, мәдәни мирас объектын арендага биргән көннән соң җиде елдан да артмаган срокта эшләр башкару бурычы.

3. Мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләве аренда шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Аукцион үткәргәндә, аренда түләвенең башлангыч күләме мәдәни мирас объектының елына 1 кв. метр мәйданына 1 сум күләмендә билгеләнә.

5. Аукцион үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләме аренда шартнамәсе гамәлдә булган чорда артырга тиеш түгел.